ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 90-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары М.Һ. Галиев, С.М. Захарова, Р.Р. Нигъмәтуллин, Р.Р. Тимергалиева, Р.Г. Хөсәенов тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 90-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ / АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН — БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ / ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2025 елның 17 июле
№ 344-VII ДС

Проект
Татарстан Республикасы
депутатлары
Галиев М.Һ.,
Захарова С.М.,
Нигъмәтуллин Р.Р.,
Тимергалиева Р.Р.,
Хөсәенов Р.Г.
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 1 – 2; 2011, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2014, № 1 – 2, № 5; 2015, № 10 (I өлеш); 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2018, № 78 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш); 2022, № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 81 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) түбәндәге эчтәлекле $2^1$ статья өстәргә:
«$2^1$ статья. **Әлеге Законда кулланыла торган төп төшенчәләр**

1. Әлеге Закон максатларында түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:
1) кече һәм урта эшкуарлык субъектлары – Федераль законда билгеләнгән шартлар нигезендә кече предприятиеләргә, шул исәптән микропредприятиеләргә, һәм урта предприятиеләргә кертеп каралган, бердәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары реестрында белешмәләре булган хуҗалык итүче субъектлар (юридик затлар һәм индивидуаль эшкуарлар);
2) гаилә предприятиеләре – түбәндәге шартларның берсенә туры килә торган кече һәм урта эшкуарлык субъектлары :
а) гаилә әгъзалары җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең устав капиталында йә хуҗалык ширкәтенең, хуҗалык партнерлыгының җыелма капиталында барлыгы 50 проценттан күбрәк өлешкә яисә акционер җәмгыятенең тавыш бирү акцияләренең 50 проценттан артыграгына ия һәм гаиләнең бер әгъзасы мондый юридик затның бердәнбер башкарма органы йә хуҗалык итүче җәмгыятьнең директорлар советы (күзәтүчеләр советы) рәисе булып тора;

б) җитештерү кооперативы, кулланучылар кооперативы, крестьян (фермер) хуҗалыгы әгъзаларының кимендә 50 проценты бер гаилә әгъзалары булып тора йә крестьян (фермер) хуҗалыгы бер граждан тарафыннан төзелгәндә – әлеге эш урыны төп булып торган крестьян (фермер) хуҗалыгының кимендә бер хезмәткәре крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгының гаилә әгъзасы булып тора;

в) индивидуаль эшкуарның төп эш урыны буенча эшли торган хезмәткәрләренең кимендә 50 проценты индивидуаль эшкуарның гаилә әгъзасы булып тора;

3) гаилә әгъзалары – ир (хатын), әти-әниләр һәм балалар (уллыкка алучылар һәм уллыкка алынганнар), бабайлар, әбиләр һәм оныклар, турыдан-туры һәм турыдан-туры булмаган туганнар (әтиләре яисә әниләре уртак булса) абый-энеләр һәм апа-сеңелләр.

2. Әлеге Законда кулланыла торган төп төшенчәләр Федераль закондагы мәгънәсендә кулланылалар.»;

2) түбәндәге эчтәлекле $22^1$ статья өстәргә:

«$22^1$ статья. **Гаилә предприятиеләре булып торучы Татарстан Республикасы кече һәм урта эшкуарлыгы субъектларына ярдәм**

1. Гаилә предприятиеләре булып торучы һәм Татарстан Республикасы гаилә предприятиеләре реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм күрсәтү Федераль законда, әлеге Законда, Татарстан Республикасының бүтән законнарында һәм норматив хокукый актларында каралган рәвешләрдә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2. Кече һәм урта эшкуарлык субъектларын гаилә предприятиеләре дип тану тәртибе һәм Татарстан Республикасы гаилә предприятиеләре реестрын алып бару тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

# АҢЛАТМА

«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты Татарстан Республикасы территориясендә гаилә бизнесы өчен хокукый гарантияләрне үстерү һәм ныгыту өчен кирәкле законнар нигезләрен булдыру максатларында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең 2025 елның 17 апрелендәге 295-РК номерлы күрсәтмәсе нигезендә төзелгән эшче төркем тарафыннан эшләнде.

Гаилә бизнесы – ул берничә мөһим социаль-икътисадый бурычны берьюлы хәл итәргә мөмкинлек бирүче уникаль күренеш. Гаилә бизнесы вәкилләре нәтиҗәле үзмәшгульлекне тәэмин итеп кенә калмыйча, яңа эш урыннары булдыруга да мөмкинлекләр ача ала. Гаилә предприятиеләренең үзенчәлеге шунда ки, алар гаилә династиясе әгъзалары тарафыннан төзелә, бу аларга бизнесны һәм нәсел кыйммәтләрен саклап калуда аерым кызыксыну булганга күрә аның тотрыклырак булуына мөмкинлек бирә.

Гаилә компанияләре күп кенә Европа һәм Азия илләрендә, шулай ук АКШ һәм Латин Америкасында икътисадның нигезе булып тора. Танылган гаилә фирмаларыннан мисал итеп Salvatore Ferragamo, Benetton һәм Fiat Group (Италия); L’Oreal, LVMH һәм Michelin (Франция); Samsung, Hyundai Motor һәм LG Group (Көньяк Корея); Германиядәге BMW һәм Siemens; Kikkoman һәм Ito-Yokado (Япония); АКШта Ford Motors Co һәм Wal-Mart Stores һәм Мексикада Televisaны алырга була.

Россия Федерациясендә гаилә предприятиеләре халык хуҗалыгының барлык тармакларында да эшләп килә: ваклап сату, икмәк-күмәч әйберләре җитештерү, терлекчелек, туристлык агентлыклары һәм туризм, җәмәгать туклануы өлкәсендә хезмәт күрсәтүче башка оешмалар эшчәнлеге, спорт, ял һәм күңел ачу өлкәсендәге эшчәнлек. Россия Федерациясе Сәүдә-сәнәгать палатасы мәгълүматларына караганда, Россиядә гаилә бизнесы илнең күпчелек «чимал булмаган» төбәкләре икътисадының нигезе булып тора, ә нефть-газ һәм таудан файдалы казылмалар чыгару өлкәләрендә аның икътисадый өлеше 30% тәшкил итә. Гомумән алганда, аерым тикшеренүләрдә Россиядә гаилә компанияләре өлеше барлык предприятиеләрнең 74%ын тәшкил итә дип күрсәтелә. Еш кына бу гаилә бизнесы булган яки гаиләнең берничә әгъзасы тарафыннан төзелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектлары.

Әмма, икътисад системасы өчен мөһим һәм әһәмиятле булуга карамастан, бүгенге көндә гаилә бизнесының рәсми законлы статусы юк, бу исә гаилә эшкуарлыгы секторы үсешенә билгеле бер киртә булып тора.

Шул ук вакытта, икътисадның аерым сегменты буларак законнар белән беркетелгән шартларда, гаилә предприятиеләре регионнарның да, тулаем илнең дә, социаль-икътисадый үсешенең төп инструментларының берсенә әверелергә мөмкин.

Моннан тыш, закон нигезендә беркетелгән «гаилә предприятиесе» төшенчәсе булу кече һәм урта эшкуарлыкның әлеге секторына статистик күзәтүләр уздыру һәм мониторинг ясау, шулай ук Татарстан Республикасы икътисады өчен аның ролен һәм әһәмиятен арттыру өчен кирәкле шартлар тудырачак.

Бүген Россия Федерациясендә гаилә эшкуарлыгыннан файдалануның нинди дә булса стратегиясе бөтенләй юк диярлек, өстәвенә милли икътисадның бу мөһим секторына федераль дәрәҗәдә законнар белән ярдәм күрсәтү дә юк.

Федераль дәрәҗәдә җайга салу булмаганга күрә, Россия Федерациясе субъектлары гаилә бизнесына ярдәм һәм аны үстерү мәсьәләләрен җайга сала торган тиешле актлар кабул итәләр. Шулай, хәзерге вакытта 20 субъектта региональ законнарда «гаилә предприятиесе» төшенчәсе беркетелгән. 10 субъектта исә (Башкортостан Республикасы, Кырым Республикасы, Владимир, Пенза, Самара, Саратов, Тверь, Тула, Ульяновск өлкәләре һәм Приморье крае) мөстәкыйль база законнары кабул ителгән.

«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты белән гаилә предприятиесе төшенчәсен беркетү каралган, ул, аерым алганда, хуҗалык җәмгыятьләренең устав (җыелма) капиталында гаилә әгъзаларының катнашу өлешенә һәм индивидуаль эшкуарда алар тарафыннан эшчәнлек башкарылуга кагылышлы таләпләргә җавап бирә торган урта һәм кече эшкуарлык субъектларын күз алдында тота. Гаилә законнары нигезендә гаилә әгъзаларына ир (хатын), әти-әниләр һәм балалар (уллыкка алучылар һәм уллыкка алынганнар), бабайлар, әбиләр һәм оныклар, турыдан-туры һәм турыдан-туры булмаган туганнар (әтиләре яисә әниләре уртак булса) абый-энеләр һәм апа-сеңелләрне кертеп карау тәкъдим ителә.

Шулай ук Татарстан Республикасы гаилә предприятиеләре реестрын алып бару карала. Кече һәм урта эшкуарлык субъектларын гаилә предприятиеләре дип тану тәртибе һәм Татарстан Республикасы гаилә предприятиеләре реестрын алып бару тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнәчәк.

**«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары актлары ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яисә кабул итүне таләп итми.

«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү кече һәм урта эшкуарлык субъектларын гаилә предприятиеләре дип тану тәртибен һәм Татарстан Республикасы гаилә предприятиеләре реестрын алып бару тәртибен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләүне таләп итә.

**«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын кабул итү Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән каплана торган өстәмә чыгымнар таләп итми.

Гаилә предприятиеләренә ярдәм чараларын финанслау кече һәм урта эшкуарлык субъектларына дәүләт ярдәме чараларын гамәлгә ашыруга бүлеп бирелә торган Татарстан Республикасы бюджеты акчалары кысаларында башкарылачак.